КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 июнь г.Казань № 472

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 октябрь, 713 нче; 2014 ел, 26 март, 187 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 18 июнь, 412 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 851 нче; 2017 ел, 23 июнь, 417 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «II. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары күрсәтә торган хезмәтләр | |
| Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш бәлән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | |
| 1. | Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат бирү |
| 2. | Гражданнарга – яраклы эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлап алуда булышлык күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 3. | Эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлап алу, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәр белеме алу максатларында гражданнарга һөнәри юнәлешне һәм Татарстан Республикасында өстәмә һөнәри белем алуны оештыру (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 4. | Татарстан Республикасында түләүле җәмәгать эшләрен оештыру (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 5. | 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытта, эш эзләүдә авырлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәр белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзләүче укуын тәмамлаган затлар арасыннан 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 6. | Эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә булышлык күрсәтү, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган, эш белән тәэмин итү органнары юлламасы буенча һөнәри уку үткән яки өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга аларны юридик зат, шәхси эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне, шулай ук тиешле дәүләт теркәве өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 7. | Татарстан Республикасында эшсез гражданнарның хезмәт базарында социаль адаптацияләү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 8. | Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 9. | Эшсез гражданнарга башка җиргә күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күчеп китүдә булышлык күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 10. | Эшсез гражданнарны һөнәргә өйрәтү һәм аларга өстәмә һөнәр белеме бирү турында, башка җирдә өйрәнүне кертеп (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары күрсәтә торган хезмәтләр | |
| 1. | Граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклык бирү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 2. | Никахлашуны дәүләт теркәвенә алу дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 3. | Балигъ булмаган уртак балалары булмаган ир-белән хатынның уртак ризалыгы буенча никахны бозуны дәүләт теркәвенә алу (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | |
| 1. | Кара һәм төсле металлар ломын әзерләү, эшкәртү һәм сату буенча эшчәнлекне лицензияләү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | |
| 1. | Урманнан файдалануны гамәлгә ашыручы гражданнардан, юридик затлардан урманнардан файдалану турында урман декларацияләре һәм хисаплар кабул итү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 2. | Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен аукцион үткәрмичә арендага бирү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 3. | Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен аукцион нәтиҗәләре буенча арендага бирү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 4. | Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләрен төзү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 5. | Урманнар үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы үткәрү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 6. | Урман кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә) |
| 7. | Урман кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү өлешендә)»; |

IV бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| «18. | Гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыру һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен үтәү белән бәйле архив белешмәләре, архив күчермәләре, архив өземтәләре, мәгълүмати хатлар бирү»; |

V бүлектә:

«Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе», «Иминият оешмалары хезмәтләре», «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы (түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация өлешендә)», «Газпром межрегионгаз Казан» акционерлык җәмгыяте» (түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация өлешендә)», «Водоканал» Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиесе» (түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация өлешендә)», «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте» (түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация өлешендә)», «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте» (түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация өлешендә)», «Күпфункцияле үзәкләр яки алар җәлеп иткән чит оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә (иярчен) хезмәтләр» бүлекчәләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе | |
|---|---|
| 1. | Кредит һәм башка финанс ресурслары алу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү |
| 2. | Эшчәнлекне маркетинг ягыннан тәэмин итү һәм бизнес-планлаштыру мәсьәләләре буенча консультация хезмәтләре |
| 3. | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт финанс ярдәмен алу мәсьәләсе буенча консультация |
| 6. | Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган программалар һәм ярдәмче программалар буенча дәүләт финанс ярдәме чаралары турында консультация бирү |
| 7. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген хокукый тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация бирү |
| 8. | Эшмәкәрлекне һәм үз эшеңне башлап җибәрүне популярлаштыруга юнәлдерелгән укыту чараларында катнашу мәсьәләләре буенча консультация бирү |
| 9. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәт ярдәме күрсәтү чаралары турында консультация бирү |
| 10. | Тышкы икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү чаралары турында консультация бирү |
| 11. | Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясеннән заем алганда поручительлек бирү шартлары һәм рәсмиләштерү тәртибе турында консультация бирү |
| 12. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен кредит оешмалары хезмәтләре буенча консультация бирү |
| 13. | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә шикаятьләр мәсьәләләре буенча консультация бирү |
| 14. | Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Татарстан |

| | |
|---|---|
| | Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан контроль-күзәтчелек чаралары үткәрелгәндә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә билдерелә торган мәҗбүри таләпләр исемлеге турында мәгълүмат бирү |
| 15. | Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының рәсми сайтында урнаштырылган эшмәкәрлек субъектларына мөнәсәбәтле тикшерүләр үткәрүнең еллык җыелма планы нигезендә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрнең планлаштырылган тикшерүләре турында мәгълүмат бирү |
| Иминият оешмалары хезмәтләре | |
| 1. | Иминиятләштерү хезмәтләре буенча консультация бирү |
| Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы | |
| 1. | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы хезмәтләре буенча консультация бирү |
| «Газпром межрегионгаз Казан» акционерлык җәмгыяте | |
| 1. | «Газпром межрегионгаз Казан» акционерлык җәмгыяте хезмәтләре буенча консультация бирү |
| «Водоканал» Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиесе | |
| 1. | «Водоканал» Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиесе хезмәтләре буенча консультация бирү |
| «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте | |
| 1. | «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте хезмәтләре буенча консультация бирү |
| «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | |
| 1. | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте хезмәтләре буенча консультация бирү |
| Күпфункцияле үзәкләр яки алар җәлеп иткән чит оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә (иярчен) хезмәтләр | |
| 1. | «Идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасында гражданнарны теркәү |
| 2. | Гражданнарга дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы составына кергән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләре бирүгә гаризалар кабул итү». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин